ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2021 Казан ш. № 226-18/тко-2021

«Волжанка» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 11-29/тко карары белән расланган озак сроклы чик тарифларга 2022 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2022 елга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озак сроклы чик тарифларны үзгәртү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2022 елларга «Волжанка» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик тарифлар билгеләү турында» 11.12.2019 № 11-29/тко-2019 карары (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 17.12.2020 № 561-21/тко-2020, 23.12.2020 № 587-45/тко-2020 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәисе А.С. Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 11-29/тко
карарына (Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
03.11.2021 № 226-18/тко-2021
карары редакциясендә) 1 нче кушымта

2020-2022 елларга «Волжанка» муниципаль унитар предприятиесе өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә календарь буенча бүленгән чик тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | | 2021 ел | | 2022 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Югары Ослан муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Волжанка» муниципаль унитар предприятиесе* | 92,00 | 122,52 | 116,77 | 116,77 | 106,18 | 106,18 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 11-29/тко карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.11.2021 № 226-18/тко-2021
карары редакциясендә) 2 нче кушымта

Каты коммуналь калдыкларны күмүгә «Волжанка» муниципаль унитар предприятиесе өчен 2020-2022 елларга чик тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| т/с | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен хәл итүче оешма исеме | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма чыгымы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Волжанка» муниципаль унитар предприятиесе | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2020 | 4355,13 | 1 | 0 | 0,21 |
| | | 2021 | 4466,80 | 1 | 0 | 0,21 |
| | | 2022 | 5087,99 | 1 | 0 | 0,21 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге